**2026 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Ак Юл торак пунктында гражданнарга үзара салым кертү турында ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№ 2 06 ноябрь 2025 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенә керүче Ак Юл торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенең Ак-Юл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ак Юл торак пунктының юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (реконструкцияләү, ремонтлау, вак таш салу, ташу, төзелеш материалларын сатып алу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Дыма-Тамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
Димтамак авыл җирлеге башлыгы



Ж.Ә.Хөснетдинов